ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕОШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 54 а нче йорт, Югары Ушма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“12” августа 2020 г. — № 12

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 нче карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «2019-2022 елларга Мамадыш муниципаль районы балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль программасы турында» 2019 елның 6 мартындагы 65 нче номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясының 1өлеше 12 пунктчасы, 50 статьясының 1 өлеше 8 пункты 1 пунктчасы нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен хәл итүдә эшне нәтиҗәле оештыру максатларында Мамадыш муниципаль берәмлеге Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (mamadysh.tatarstan.ru), Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Югары Ушма авыл җирлеге
Мамадыш муниципаль районының
Башкарма комитет җитәкчесе /И.З.Исмагилов/